Татарстан РеспубликасыӘлмәтмуниципаль районы
Иске Михайловка авыл җирлегенең Иске Михайловка авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

23 ноябрь 2019 ел №2

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Иске Михайловка авылында тавыш бирү нәтиҗәләре турында" гражданнар җыены хисап комиссиясенең 2019 елның 23 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә, Татарстан республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Иске Михайловка авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Иске Михайловка авылында узган халык җыенын үткәрелгән дип таныргa, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлегенең Иске Михайловка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: тракторга асылмалы җиһазлар сатып алуга?» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Иске Михайловка авылы, 43 йорт, территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

Халык җыенында рәислек итүче
Иске Михайловка
авыл җирлеге башлыгы И.М. Абдуллин